**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 166** **«31» гыйнвар 2025 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 22 июлендәге 213-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 октябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Уставы нигезләмәләрен, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Бигеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алынганнан соң билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Карар дәүләт теркәве узганнан соң һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Р.Валеев**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советының
2025 елның 31 гыйнварендәге
166 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Бигеш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми исеме – «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге», кыскартылган атамасы «Бигеш авыл җирлеге» (текст буенча алга таба-авыл җирлеге)»;

2. 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

3. 11 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацында «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле референдум комиссиясе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма органы» сүзләренә алмаштырырга.;

4. 12 статьяның 3 өлешендә дүртенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль законда билгеләнгән очракларда муниципаль сайлаулар тиешле сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан билгеләнә.»;

5. 13 статьяда:

а) 5 өлештә «җирлек сайлау комиссиясен» сүзләрен «җирле референдум әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга.;

б) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Инициатив төркем үтенечнамәсен җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе караганда, җирлек Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне җирлек Советы билгеләгәндә, тиешле депутат аны чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган хәлләр турында аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән депутат җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе, җирлек советы утырышларын уздыру көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча алдан ук, аларны уздыру вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр ителергә тиеш.»;

в) 12 өлештә «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле референдум әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.;

6. 18.1 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 - 7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.;

7. 22 статьяның 3 өлешендә:

а) 2,3,4,5.1 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;»

8. 28 статьяның 1өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланучы 7 депутаттан тора.»;

9. 29 статьяда:

а) 7 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.;

б) 8 өлештә «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга.;

10. 32 статьяда:

а) 14 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 31 пункт өстәргә:

«31) муниципаль хокукый актларны бастыру, муниципаль берәмлек халкы игътибарына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы булдыру;»

11. 37 статьяның 3 өлешендә «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «муниципаль сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.;

12. 39 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

б) 3 өлештә «1 өлешенең 1-7, 10 һәм 11 пунктларында» сүзләрен «1 өлешенең 1-7, 10, 10.1 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.;

в) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;

13. 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. Җирлек башлыгы бер үк вакытта җирлек советын һәм җирлек башкарма комитетын җитәкли.»;

14. 41 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.;
15. В пункте 2 части 7 статьи 42:
а) «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга.;
б) «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органында, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасында катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башлыгына (Рәисенә) алдан хәбәр итеп, түләүсез нигездә катнашу;»;
16. 44 статьяның 4.1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга»;
17. 47 статьяда:
а) 5 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;
б) 9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә ала.»;
18. 69 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«69 Статья муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы җирлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми игълан итү булып түбәндәгеләр тора:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында рәсми бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык по ФС77-60244 бирелгән 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә «Яңа Зәй» газетасында, массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык по ФС7-4764 ПИ бирелгән 30.11.2007 массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә законнарның үтәлешен күзәтчелек итү хезмәте;

2) Зәй муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру https://zainsk.tatarstan.ru.

3) адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру:

Татарстан Республикасы, Зәй районы, Бигеш ав., Клуб ур., 1;

Татарстан Республикасы, Зәй районы, Карман ав., Үзәк ур., 43 в;

Татарстан Республикасы, Зәй районы, Түбән Лоҗы ав., Үзәк ур., 43а;

Татарстан Республикасы, Зәй районы, Югары Лоҗы ав., Үзәк ур., 29;

Татарстан Республикасы, Зәй районы, Кәрәкәс ав., Үзәк ур., 71а;

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Татарстан Республикасы, Зәй районы, Бигеш ав., Клуб ур., 1 йорт (җирлек башкарма комитеты), Татарстан Республикасы, Зәй районы, Дүрт Мунча ав., Клуб ур., 117А йорт (китапханә).

4. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр аларны имзалаган көннән алып җиде көн эчендә, таратуы федераль закон белән чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, халыкка игълан ителә.

5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар имза салынган көннән үз көченә керә, әгәр акт үзе тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка чыгару (рәсми бастырып чыгару) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән бөтен игътибарга җиткерелә.»;

18. 72 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары муниципаль милектәге электр челтәре оешмасы яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эшләүче территориаль челтәр оешмасы системасындагы электр челтәре хуҗалыгы объектларын, Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».